**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «01» декабреннән № 273

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзэге - Яңа Чишмә авылыннан 11 километрдан ераграк урнашкан авыл торак пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен кулланучылар кооперациясе оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 03 июнендәге 242 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы составына керүче, ерак торак пунктларда яшәүче авыл халкын беренче чиратта кирәкле товарлар белән тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, шул исәптән, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар җитештерүче, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне башкаручы физик затларга субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга салучы муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында, һәм Россия Федерциясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм кайбер актларның нигезләмәләрен гамәлдән алынган дип санау турында» Россия Федерциясе Хөкүмәтенең 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы район үзәкләреннән 11 километрдан ераграк урнашкан Татарстан Республикасы авыл торак пунктларына кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 20 ноябрендәге 887 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзәге – Яңа Чишмә авылыннан 11 километрдан ераграк урнашкан авыл торак пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен кулланучылар кооперациясе оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 03 июнендәге 242 номерлы карарына (алга таба Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче бүлекнең 1.1 пунктындагы 3 нче абзацында «беренче чиратта кирәкле товарларда» сүзләре алдыннан «исемлеге россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Беренче чиратта кирәкле социаль әһәмиятле азык-төлек товарларының аерым төрләренә, иң кирәкле социаль әһәмиятле азык-төлек товарларының аерым төрләре исемлегенә, иң чик мөмкин булган ваклап сату бәяләре билгеләнергә мөмкин булган беренче ихтыяждагы социаль әһәмиятле азык-төлек товарларының аерым төрләре исемлеген һәм сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган хуҗалык субъектына билгеле бер күләмдә сатып алган өчен акчалата түләү рөхсәт ителми торган социаль әһәмиятле азык-төлек товарларының аерым төрләре исемлеген раслау турында» 2010 елның 15 июлендәге 530 номерлы карары белән расланган» сүзләрен өстәргә.

1.2. 1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.9 п. өстәргә: «Агымдагы финанс елының узган чорында субсидияләр бирүнең нәтиҗәсе булып нәтиҗәлелек күрсәткечләре ярдәмендә бәяләнүче Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзәге - Яңа Чишмә авылыннан 11 километр ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының авыл торак пунктларында сәүдә хезмәте күрсәтүнең (күчмә сәүдәнең) ышанычлылыгы (өзлексез торуы) тора:

- зурлыгы 0,7 дән ким һәм 1 дән артык булмаган, күчмә сәүдәнең Татарстан

Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзәгеннән - Яңа Чишмә авылыннан 11 километр ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл торак пунктларын колачлау коэффициенты.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы үзәгеннән - Яңа Чишмә авылыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл торак пунктларын күчмә сәүдә белән колачлау коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнә:

КсП =О факт /Огр

биредә:

Офакт - агымдагы елның хисап чорында күчмә сәүдә гамәлгә ашырылган, Яңа Чишмә муниципаль районы үзәгеннән - Яңа Чишмә авылыннан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл торак пунктлары саны;

Огр - Яңа Чишмә муниципаль районы үзәгеннән - Яңа Чишмә авылынан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл пунктларына күчмә сәүдә графигы нигезендә агымдагы елның хисап чорында урынга чыгу каралган авыл торак пунктлары саны.

1.3. 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.9 п. өстәргә: «Субсидия алучы әлеге Тәртипнең 2 бүлегенең 2.5 пунктында күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокукы булган зат тарафыннан имзаланган килешү проектын Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырмаган очракта килешү төзүдән читләшкән дип танылa.».

1.4. 2 бүлекнең 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Субсидия бирү өчен нигез булып Комиссия тарафыннан субсидия алу турында карар кабул ителгән көннән алып җиде эш көне эчендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасында билгеләнгән типлаштырылган форма нигезендә Яңа Чишмә муниципаль районы үзәгеннән - Яңа Чишмә авылыннан 11 чакрым ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының авыл торак пунктларына

беренче кирәк-ярак товарларны китерү буенча хезмәт күрсәтүләргә субсидияләр бирү турындагы килешү тора.»;

1.5. 2 бүлекнең 2.6. пунктын Үз көчен югалткан дип танырга.

1.6. Кararга 2 нче кушымтаны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның «01» декабреннән
273 номерлы карарына
кушымта

Яңа Чишмә муниципаль районы үзәгеннән – Яңа Чишмә авылыннан 11 километрдан ераграк урнашкан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының авыл торак пунктларына беренче кирәк-яраклар китерү буенча чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарын каплауга Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү комиссиясе составы

Комиссия рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Фасахов Ринат Рифгать улы | - | Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |

Комиссия рәисе урынбасары:

| | | |
|---|---|---|
| Исхакова Луиза Камил кызы | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (икътисад буенча); |

Комиссия секретаре:

| | | |
|---|---|---|
| Завалишина Наталья Александровна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча) |

Комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Габетдинов Ренат Хәлфәт улы | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары (инфраструктур үсеш буенча) |
| Иванова Нина Николаевна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм муниципаль заказ бүлеге башлыгы |

| | | |
|---|---|---|
| Кәбирова Диләрә Нәкыйп кызы | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы |
| Мартышова Светлана Вячеславовна | - | «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге каршындагы иҗтимагый Совет рәисе (килешү буенча) |